DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

12+

№18 (111)

19 июнь 2014 ел



# Җыр – рухи үсеш мөмкинлеге

**Бүген КФУ студентлар өчен зур мөмкинлекләр ача. Белем алу, фәнни юнәлеш өлкәсендә генә түгел. Студентлар иҗади яктан да ачыла, үсә, сәләтләрен үстерә ала. Университетта эшләп килә торган күпсанлы иҗади коллективлар эшчәнлеге, аларның уңышлары моның чыннан да шулай булуы хакында сөйли. Һәм иң мөһиме – бу юнәлештә студентларның сайлау мөмкинлеге зур. Шигырь язамы ул, проза белән кызыксынамы, җыр-биюгә өстенлек бирәме, рәсем белән шөгыльләнәме – монысы һәркемнең үз эше. Араларында берничә иҗат төрен үзләштерергә өлгерүчеләр дә юк түгел.** *Дәвамы 3 биттә*

## Вакыйгалар эзеннән

Шушы көннәрдә КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына Казакъстанның Алматы шәһәре Туран университеты профессоры **В.САЛАГАЕВ** һәм Әл-Фараби исемендәге Казакъ дәүләт университеты доценты **Х.МӨХӘММӘДИЕВ КИЛДЕ**. Максатлары – институтта телләргә өйрәтүнең торышын тикшерү, бу өлкәдәге яңа методикалар, яңалыклар белән танышу һәм ике арада хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре булдыру.

• • • •

11-13 **ИЮНЬ** көннәрендә Гиссенда **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ** һәм Ю.Либига исемендәге **ГИССЕН УНИВЕРСИТЕТЫ** арасындагы **ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕҢ 25 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ** уңаеннан рәсми чаралар уздырылды. Бу уңайдан ректор И.Гафуров җитәкчелегендәге КФУ делегациясе алман университеты чакыруы буенча анда булып кайтты. И.Гафуров үз чыгышында вузара хезмәттәшлекнең Open Lab кебек инновацион формаларының киңәюе мөһимлегенә басым ясады.

• • • •

16 **ИЮНЬ** көнне Казан Кремлендә Татарстан Президенты **Р.МИҢНЕХАНОВ** Чехия республикасының **КӨНЬЯК МОРАВ КРАЕ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** белән очрашты. Бу очрашуда **КФУ** ректоры **И.ГАФУРОВ** та катнашты. Әлеге очрашу16-18 июнь көннәрендә булды. Ул 2013 елның апрель аенда Татарстан делегациясенең Чехиягә булган визитына җавап рәвешендәге күрешү иде.

• • • •

17 **ИЮНЬ**нән КФУның Вузга кадәрле белем бирү үзәге өлкән сыйныф укучылары – халыкара, Россия һәм республика олимпиадалары һәм фәнни конференция җиңүчеләре өчен профильле **«КВАНТ» МӘКТӘП-ЛАГЕРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ СМЕНАСЫН АЧЫП ҖИБӘРДЕ**. 18 көн эчендә яшь физик, математик, биолог һәм астрономнар КФУның «Яльчик» спорт-сәламәтләндерү комплексында фәнни лабораторияләрдә һәм иҗади төркемнәрдә шөгыльләнәчәк.

• • • •

17 **ИЮНЬ** көнне **КФУ**га Төрек республикасының Мәскәүдәге Коралллы көчләр Вәкаләтлелегенең атташесы **ДЖИХАТ ЯЙДЖЫ ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Мактаулы кунак белән бергә Төрек республикасының Казандагы генераль консулы Сабри Тунч Ангылы да килгән иде. Джихат Яйджы Казан университетының тарихы белән танышканнан соң, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәтү институтының төрек телен өйрәнүче студентлары белән аралашты.

• • • •

**20 ИЮНЬ** көнне **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ БУЛАЧАК СТУДЕНТЛАРЫ ӨЧЕН ИШЕКЛӘРЕН АЧЫП ҖИБӘРӘЧӘК**. Быел документларны кабул итү 5 көнгә алдан башлана. Димәк, абитуриентлар 25 июльгә кадәр кирәкле документларын үзләре теләгән институтларга тапшыра алалар. Кабул итү кампаниясе 20 августка кадәр эшләячәк. Тулырак мәгълүматны Кабул итү комиссиясе сайтында табарга мөмкин.

• • • •

КФУ Камчатка вулканнарына менү сериясе экспедицияләрен оештыручыларның берсе булып тора. Шундый бер тауның башында **УКУ ЙОРТЫ ФЛАГЫ** да урнаштырылды. Альпинистлар төркемен Казан университетын тәмамлаган Нияз Гәрәев җитәкли. Экспедициядә катнашучылар 18 көн эчендә 50 километрдан артык араны үтәләр.

• • • •

Шушы көннәрдә **АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ**ның Абай ис. **КАЗАКЪ МИЛЛИ ПЕДАГОГИК УНИВЕРСИТЕТЫНА ВИЗИТЫ ТӘМАМЛАНДЫ**. Очрашуның нәтиҗәсе итеп, ике уку йорты арасында хезмәттәшлек килешүе төзелде. Вузлар фәнни-методик, фәнни, һөнәри белем бирүне кадрлар белән һәм мәгълүмати тәэмин итү, фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлек буенча килешү төзеде. Документларга Алабуга институты директоры Е.Мерзон һәм КМПУның беренче проректоры М.Ермаганбетов кул куйды. Очрашу барышында шулай ук студентлар һәм укытучылар алмашу, уртак фәнни чаралар үткәрү турында сөйләштеләр.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

● Эшлекле сөйләшү

# Без – бер адым алда!



16 июнь көнне Фундаменталь медицина һәм биология институты базасында Кайгыртучанлык советы утырышы узды. Аны совет җитәкчесе ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов алып барды.

Утырыш башланганчы, **Президент** КФУның укыту-фәнни лаборатор кампуслары белән танышып чыкты. Инженерия институты, Инжиниринг үзәге, Фундаменталь медицина һәм биология институты биналарын, андагы яңа үзгәрешләрне карады.

Утырышта күргәннәрдән алган тәэсирләре һәм фикер-тәкъдимнәре белән уртаклашты: «Уку йорты үсә, актив рәвештә алга бара, элек булмаган яңа юнәлешләр ачыла. Университет төрле сәнәгать оешмалары белән тыгыз бәйләнештә торырга тиеш, чөнки алар сезнең эшләнмәләргә мохтаҗ», – диде. Шул уңайдан, узган атнада гына КФУның Инжиниринг үзәгенә булган визиты турында да берничә сүз әйтеп узды. Биредә лекцияләрне нәкъ менә заводның алдынгы менеджерлары һәм инженерлары укый да инде.

«Фундаменталь медицина һәм биология институтындагы үзгәрешләр дә таң калдырды. Биредәге фәнни үзәкләр Россиянең медицина мәгарифе системасына зур үзгәрешләр алып киләчәк. Безнең уку йортында симуляцион үзәк булу – республика өчен генә түгел, ә илебез өчен зур горурлык», – диде Президент. Җитәкче сүзләренчә, университет – ул эшләнмәләр үзәге. Уку йортының дәрәҗәсен күтәрү өчен, күп көч куярга кирәк, ләкин бу үзеннән-үзе барлыкка килми. «Команда белән эшләнә торган эш бу. Монда башкарылганнарны башка уку йорты җитәкчеләренә күрсәтергә кирәк. Фикер йөртү белән генә шөгыльләнергә түгел, ә эшләргә кирәк икәнен аңласыннар. Бүген без күргәннәрне хәтта Карнеги-Меллон университеты белән чагыштырып булмый», – диде Президент.

Алга таба сүз алган КФУ ректоры **Илшат Гафуров** Р.Миңнехановка уку йортына биргән югары бәясе һәм ярдәме өчен рәхмәт сүзләре җиткереп: «Бу – безнең уртак хезмәт. Республика җитәкчелеге ярдәменнән башка без бу уңышларга ирешә алмас идек», – диде. Шулай ук тагын бер кат Президентка һәм Дәүләт Советы депутатларына КФУда мәгарифне үстерүгә дәүләт ярдәме канунын кабул иткәннәре өчен рәхмәт сүзләре җиткерде. Утырышта Казан университетын тәмамлаган ТР Премьер-министрының беренче урынбасары А.Песошинны Кайгыртучанлык советы составына алу тәкъдиме бер тавыштан кабул ителде.

Алга таба ректор уку йортыбыздагы алдынгы юнәлешләрнең үсеше турында сөйләде. «Казан университеты өчен, Президент кушуы буенча Чернышевский урамындагы бинаны реконструкцияләп, аны Нефть һәм кара алтын-газ технологияләре институтына тапшыру бик мөһим чара булды. Без, студентлар мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнә алсын өчен, бик күп аудиторияләргә, ике йөзгә якын кеше сыйдырырлык заманча җиһазландырылган залга ия булдык. Ләкин без аларны, планлаштырганча, лабораторияләр өчен файдалана алмадык, шуңа күрә яңа төзелеш эшләре башларга туры килде. Казан университетының 210 еллыгын бу эшләрне төгәлләп каршы алырбыз, дип ышанам. Белгечләр, яшь галимнәр инде биредә эшләргә әзер. Алар чит илләрдә төрле югары уку йортларында стажировка узалар. Тормышка ашырылачак проектлар да бар, аларны гамәлгә куюны төрле нефть компанияләренең түләргә әзер торуы сөендерә», – диде.



Быел шулай ук А.М.Бутлеров ис. Химия институтында төзелешләр тәмамланыр дип планлаштырыла. Биредәге корпуста барлыгы 30дан артык лаборатория урнашачак. Беренчедән, алар халыкара масштаблы, икенчедән, дисциплинаара. Уку йортындагы 7 институтның мәнфәгатьләрен кайгыртачак һәм кара алтын табу, аны эшкәртү, кара алтын-газ, химия, биомедицина һәм фармацевтика өлкәсендә булган бурычларны хәл итүдә, функциональ материал ясауда ярдәм итәчәк.

И.Гафуров уку йортындагы тагын бер алдынгы юнәлеш – медицина һәм фармацевтикага да тукталды. «Университет бөтен заман таләпләренә тулысынча туры килгән медицина кластеры булдырды. Бүгенге көндә инде, үзебезнең галимнәрдән тыш, бу өлкә буенча читтән чакырылган 20ләп галим эшли. Ләкин әлегә уку йортының медицина юнәлеше буенча белгечләр әзерләү өчен дәүләт аккредетациясе юк, чөнки бу юнәлеш буенча абитуриентлар әле узган ел гына кабул ителде һәм без аккредетацияне беренче чыгарылыштан соң гына ала алабыз. Бу 4-6 ел дигән сүз», – диде ректор. Аның сүзләренә караганда, ул РФ Премьер-министры Д.Медведевтан әлеге канунга үзгәрешләр кертүне сораган. РФ Мәгариф һәм фән министры Д.Ливанов Россиядәге алдынгы 40 уку йортындаяңаюнәлешәләргә аккредетация бирү процессын тизләтүне тәкъдим иткән. Бу күпмедер вакыт таләп итә торган процесс, шуңа күрә И.Гафуров совет әгъзаларыннан быелгы уку елына ике төркем туплауга рөхсәт алды.

Ректор шулай ук Президентка Волков урамында урнашкан 2нче номерлы хастаханә бинасын КФУга тапшыру процессын тизләтү үтенече белән мөрәҗәгать итте. Бу эш ил башлыгы тарафыннан кушылган булса да, документлар тоткарлана икән.

КФУның 2013-2019 елларга Үсеш Дәүләт программасы проектының әзерлеге турында Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин мәгълүмат бирде. Россия вузлары арасында QS предмет рейтингы күрсәткечләре белән таныштырды. Әйтергә кирәк, КФУның күрсәткечләре яхшы.

Алга таба «Калужский фармацевтический кластер» коммерцияле булмаган партнерлыгы, РФдәге «Rohde&Schwarz Gmbh, Co&KG»

Вәкиллеге, НПО «Андроидная техника» фәнни-сәнәгать оешмасы җитәкчеләре чыгышларында үзләренең университет белән хезмәттәшлек үсеше стратегиясе турында сөйләделәр. Чыгышлар үзара килешүләргә кул кую белән төгәлләнде. Шулай ук КФУ белән «ТИСБИ» идарә университеты арасындагы үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә дә кул куелды.

Йомгаклап, ТР Президенты, КФУның Кайгыртучанлык советы җитәкчесе Р.Миңнеханов, утырышта катнашучыларга мөрәҗәгать итеп: «Үсеш темпын киметергә ярамый. Яхшы нәтиҗә өчен тырышырга, бөтен эшләрне дә мантыйгый рәвештә ахырына кадәр җиткерергә кирәк», – диде һәм уңышлар теләде.

*Universmotri.ru фотолары*

● Атна ачышы

# «Хезмәттәшлекнең яңа эрасы»

**Алинә САДЫЙКОВА**

17 июнь көнне Казан федераль университетына РИКЕН делегациясе визит ясады. Делегация составында фундаменталь тикшеренүләр класстеры директоры Кохеи Тамао, доктор Кацунори Танака һәм Вон Кюн Кан ханым бар иде.

Чараны ректор **И.Гафуров** ачып җибәрде. Ул кунакларны сәламләп, Япония белән булган яхшы мөнәсәбәтләр турында сөйләде. «РИКЕН белән Казан университетының аралары якынаюга мин бик шат. Безнең өчен бу бик зур әйбер, чөнки без партнерларыбызны алар белән бик озак вакыт эшләячәгебезне күз алдында тотып сайлыйбыз», – диде.

К.Тамао, үз чиратында, университетыбыз җитәкчелегенә рәхмәт сүзләре җиткерде һәм, хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе итеп, ачылачак лабораториягә өметләрен баглады: «Бүгенге хезмәттәшлегебез – КФУ белән төзелгән инде икенче килешү. Ачылачак лаборатория, тикшеренү эшкәртмәләрен булдыру белән беррәттән, академик мобильлеккә дә булышлык итәр дип өметләнәм. Гомумән, бүгенге дата Россия-Япония хезмәттәшлегенең яңа эрасы буларак мәңгеләштереләчәк». Кохеи әфәнде Казан университетыннан проектның эшчәнлегенә булышлык итүне үтенде.

И.Гафуров, университетка йөкләнгән бурычларның вакытында үтәлеп баруына басым ясап, лабораториянең проблемалары булмаячак дип ышандырды. «Иң мөһиме: хезмәттәшләребез катлаулы һәм четерекле мәсьәләләр килеп чыгу белән, безгә мөрәҗәгать итсеннәр. Ул вакытта проблеманы чишү юлларын бергә эзләрбез», – дип өстәде. Уку йортыбыз җитәкчесе бүгенге



көндә чит ил вәкилләренә КФУ мәйданында тикшерү эшләре алып бару өчен ишекләр ачык икәнен, уку йортының әлеге эшчәнлек өчен 200 грант бирә алачагын да әйтте.

Сәламләү сүзләрен алышканнан соң, ике як та меморандумга кул куйды. Килешү буенча КФУ яңа лаборатория өчен мәйдан булдыра, проектны кадрлар һәм заманча техник җиһазлар белән тәэмин итә. РИКЕН исә лабораторияне җитәкләргә һәм фәнни тикшеренүләр үткәрергә ярдәм итә.

Кунаклар КФУның Тарих музеенда уку йорты тарихы белән танышканнан соң, **К.Тамао** уку йортыбызда «Элементоорганическая химия, усиленная новой серией универсальных объемных защитных групп «Rind» исемле лекциясен укыды.

Шул ук көнне, килешү нигезендә, Россия-Япон фәнни-тикшеренү лабораториясе – «Биофункциональ химия лабораториясе» ачылды. Аның җитәкчесе органик химия кафедрасы доценты А.Корбангалиева булачак.

*Влад Михневский фотолары*



● Иҗат

# Җыр – рухи үсеш мөмкинлеге

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Башы 1нче биттә.**

Бүген Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында үзенчәлекле хор эшләп килә. Ул иҗатта әле тәүге адымнарын гына ясый. 2013 елның 1 декаберендә Институтның Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге базасында оешкан бу коллектив башкалардан яшь булуы белән аерылып тора. ФһМБИның социаль-тәрбия эшләре бүлеге җитәкчесе Эльвира Закирова сүзләренчә, өлкән курс, бигрәк тә беренче курс студентлары, җырлау теләкләрен белдереп, еш мөрәҗәгать иткәннәр. Хор оештыруга ихтыяҗ зур булгач, институтта Татар яшьләр ансамбле үз эшчәнлеген башлап җибәрә. Бүген әлеге хор шул исемне йөртә. Ансамбльгә Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары гына түгел, башка бүлек һәм хәтта институтларда укучы һәм җыр белән кызыксынучы студентлар да тартыла. Ансамбльнең дебют чыгышы институтта үткәрелгән 8 Март бәйрәме кичәсендә булган.

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Татар яшьләр ансамбле татар халык җырларын да, замандаш композиторларыбыз иҗат иткән җырларны да башкара. Хорның җитәкчесе, төп педагогы – С.Сәйдәшев исемендәге югары сәнгать мәктәбенең өлкән укытучысы Фатыйма Әхмәдиева.



Ул студентларны профессиональларча җырларга, дөрес итеп тын алырга өйрәтә. Хормейстер вазифасын өлкән курс студенты Алсу Вәһапова башкара. Хорга йөрүчеләр җырлап кына калмыйча, билгеле бер бию хәрәкәтләрен дә үзләштерә. Хореография серләренә дә аларны өлкән курс студентлары – Динара һәм Айнура Кәримовалар төшендерә.

«Классик юнәлешле хорлардан аермалы буларак, ФһМБИ хоры заманча, мобиль, яшь. Коллектив тамаша элементлары, бию хәрәкәтләренә бай чыгышларга өстенлек бирә», – ди Эльвира Закирова.

Чагыштырмача күптән түгел оешканга күрә, әлегә ансамбль үзен төрлечә сыный. Күптән түгел хорчылар «Ягымлы яз» фестиваленең сайлап алу турларында катнашкан. Алар чыгыш ясаган тагын бер зур чара – 9 Май көнне Ирек мәйданында уздырылган «Поющая Казань» проекты. Биредә хорчылар, башка хорлар белән берләштән, сугыш турындагы җырлар тезмәсен башкарган. Шул рәвешле әкренләп билгеле бер иҗади тәҗрибә туплана.

Һәр коллективның үсеше өчен вакыт кирәк. Әлегә хорга нибары 12 кеше йөри. Әлбәттә, тулы кыйммәтле хор өчен бу гына аз. Шулай да ансамбль җитәкчеләре яңа уку елында җырлау теләге белән янучы, яңалыкка омтылучы егет-кызларның киләчәгенә, коллективның тулылануына өмет баглый.

Ә хорга кабул ителү өчен төп таләп ул – теләк. Җырлыйсы килгән, әмма тавышы артык көчле булмаган студентлар да биредә иҗади яктан ачылып, үсеп китә. Җитәкчеләре Фатыйма Әхмәдиева студентларның тавыш куелышына аеруча игътибар итә, бу юнәлештә һәрберсе белән шәхси шөгыльләнә. Ансамбль җырларны әзер көйгә кушылып та, акапелла да башкара. Студентлар өчен филология нигезләрен үзләштерү белән берләштән, музыка серләренә дә төшенү мөмкинлеге булу киләчәктә аларның белемле, рухи яктан бай белгеч булачагына ишарәли. Моның шулай икәнлегенә хорга йөрүче студентлар үзләре дә ышана.

● Зөлфия Ибләминова: *Мин хорга аның ачылган көненнән бирле йөрим. Хорга кеше җыюларын белдем дә, барырга булдым. Мин җырларга яратам, ә монда шундый шәп мөмкинлек туды. Биредә шөгыльләнү миңа бик ошый. Җитәкчебез Фатыйма Касыймовна безне дөрес итеп җырларга, үзеңне сәхнәдә дөрес тоту кагыйдәләренә өйрәтә. Хорга йөрү – җырлау сәләтен үстерү өчен зур мөмкинлек, дип саныйм.*

● Айгөл Данелия: *Җитәкчебез бик әйбәт. Ул безгә һәрвакыт файдалы киңәшләрен бирә. Хорда җырлап, профессиональ яктан үстем, билгеле бер уңышларга ирештем. Киләчәктә дә бу шөгылемне дәвам итәргә уйлыйм, чөнки бу мине рухи яктан баета.*

● Белем баскычлары

# Филологиядә ике яңа белгечлек

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



**Яңа уку елында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә филология юнәлеше буенча ике яңа белгечлек ачыла: «Татар теле һәм әдәбияты, хореография нигезләре», «Татар теле һәм әдәбияты, журналистика».**

«Боларның барысы да уйлап эшләнелә. Бүген без базар шартларында көндәшлеккә сәләтле белгечләр әзерләүне күз уңында тотабыз. Эшкә кайсы оешмага гына бармасын, бездә укып чыккан студентлар югалып калырга тиеш түгел», – дип белдерә Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге мөдире Әлфия Юсупова.

Татар филологиясе бүлеген тәмамлаган студентларның шактый өлешежурналистикаюнәлешендәэшли. Бүгенге мәгълүмати технологияләр заманы шартларында исә белемле, профессиональ яктан җитлеккән, анализлау сәләтенә ия журналистларга ихтыяҗ зур. Шуңа да «Татар теле һәм әдәбияты, журналистика» белгечлеген ачу үзен тулысынча аклый. Бу белгечлекне үзләштергән студентлар зур тормышка практик һәм теоретик яктан әзерлекле журналистлар булып чыгачак. Әлбәттә, филология юнәлешендә төп фәннәр булып татар теле һәм әдәбияты укытылачак, һәм бу юнәлеш, нигездә, татар теле һәм әдәбияты белгечләрен, укытучыларын әзерләүне күз уңында тота.

Быел ачылачак ике яңа белгечлекнең һәркайсына 12шәр бюджет урыны каралган. БДИ баллары түбәнрәк булган абитуриентлар өчен түләп уку мөмкинлеге дә булачак. Сынауларга килгәндә, филология юнәлеше буенча укырга керергә теләк белдерүчеләр татар теле, рус теле, рус әдәбияты, җәмгыять белеме; педагогика юнәлешенә өстенлек бирүчеләр исә татар теле, рус теле, математика, җәмгыять белеменнән бердәм дәүләт имтиханы тапшырырга тиеш. Ә мәнә бию сәнгате буенча имтихан бирергә кирәк булмаячак. «Без бу очракта абитуриентларга ышанабыз. Бер дә биеп карамаган кеше, билгеле, бу белгечлек буенча укырга кермәячәк. Шуңа бу уңайдан ниндидер проблема булыр дип уйламыйм.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы – милли йөзне саклаучы кеше. Мәктәптә татар халкының тарихы, мәдәнияте белән бәйле чараларның күбесе аның катнашында уза. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы бию сәнгате нигезләрен дә белсә, бу аның өчен дә, татар мәктәбе өчен дә өстәмә плюс булачак», – ди Әлфия Юсупова.

Билгеле булганча, хәзерге көндә филология юнәлешендә инде студентлар кабул ителгән тагын ике белгечлек буенча белем бирәләр: «Татар теле һәм әдәбияты, тәрҗемә», «Татар теле һәм әдәбияты, мәгълүмати технологияләр». Аларның икесендә дә студентлар чит телне тирәнтен өйрәнә. Педагогика юнәлеше исә үз эченә «Татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле», «Татар теле һәм әдәбияты, кытай теле», «Татар теле һәм әдәбияты, төрек теле» белгечлекләрен ала.

● «Алтын каләм»



# Унтугызынчы старт!

**Илүсә Арикеева,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Бүген, 17 июнь көнне, «Волга» яшьләр үзәгендә XIX **«Алтын каләм – Золотое перо»** Республикакүләм фестивале старт алды. Ачылу тантанасында фестивальнең «анисе» Римма Атлас кызы Ратникова катнашучыларга «Алтын каләм» иләгә аша узып кына, сез үзегезнең журналистика өлкәсендә нинди урын тотачагызны аңлый аласыз», – дип белдерде.

Алдагы 5 көн дәвамында яшь журналистлар Казан федераль университетында укырга керү мөмкинлеге бирә торган, фестивальнең иң зур бүләге булган Гран-при өчен көч сынашачаклар. Бәйге бу ел да кызу булырга охшый!

*Алсу Закирова фотосы*

● Телләр белгән – илләр гизгән

# «Мин – беренче карлыгач!»

Алинә САДЫЙКОВА



Шушы көннәрдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 2 курс магистры Гүзәл Шәмсиева Төркиядә гыйлем эстәп кайтты. Аның әлеге үзенчәлекле сәяхәте турында Гүзәл дәүләт имтиханы биреп йөргәндә сораштырып алдым.

**– Гүзәл, син бу сәяхәткә максатчан әзерләндеңме, әллә Төркиягә бару идеясе көтмәгәндә туды-мы?**

- Минем Төркиягә һәр баруым да ничектер көтмәгәндә килеп чыга. Әлеге сәяхәтем дә алдан билгеле булмады. Остазларым: профессор Фәрит Йосыпов һәм профессор Фәнүзә Нуриева, мине үзләренә чакырып алып, «Мәүләнә» программасы турында сөйләделәр. Һәм шул ук көнне минем кандидатура расланды да. Бу хәбәрне бик шатланып кабул иттем. Соңыннан кирәк булган мәгълүмат белән тиешле документларны җибәрдек. Әлеге программа өчен җаваплы координаторлар Чулпан Газиева һәм Юрий Черкасов белән гел элемтәдә тордым.

**- «Мәүләнә» программасы белән якыннанрак таныштырып кит әле.**

- Бу программа Казан федераль университеты белән Төркиянең Фрат университеты арасындагы килешүе нигезендә тормышка ашырыла. Аның буенча чит ил студентлары һәм академиклары Төрек университетларында укый һәм укыта ала. Барлык чыгымнарны Төркия үзе күтәрә. Бу хезмәттәшлек әле күптән түгел генә оешты һәм безнең уку йортыннан беренче барган кеше мин булдым. Гомумән, Татарстаннан да үзем генә бардым. Миннән тыш та тәкъдим ителгән студентлар бар иде, тик алар билгеле бер сәбәпләр аркасында бара алмыйча калдылар. Яз көне укытучым Фәнүзә апа Нуриева да, Фрат университетына килеп, 24 көн буе төрек студентларын белем серләренә төшендерде.

**- Анда ниләр белән шөгыльләндең?**

- Мин Фрат университетының Социаль һәм инсани белемнәр институтында укыдым. Анда үземнең магистрлык программасы курсы белән тәңгәл килгән фәннәрне үзләштердем, зачет-имтиханнар бирдем. Шулар белән беррәттән төрек телен өйрәндем һәм магистрлыкэшемнеяздым. Төрек китапханәләрендә магистрлык хезмәтемә туры килгән мәгълүматлар тупладым. Аларның кайбер өлешләрен тәрҗемә итеп, магистрлык диссертациямдә дә кулландым.

**- Ял итәргә вакытың кала идеме соң?**

- Күп вакытым укуга багышланган булса да, ял итәргә дә өлгерә идем. Төркиялеләр белән генә түгел, Азәрбайҗан, Кения, Тайланд, Сүрияләр белән аралаштым. Шулай ук, университет күләмендә уздырылган шигырь кичәсендә катнаштым (*фотода*). Мин биредә барлыгы 8 ай тордым. Әйткәндә күп кебек, ләкин ул вакыт бик тиз үтеп китте.

**- Фрат университеты синдә нинди тәэсирләр калдырды?**

- Миңа Фрат университеты бик ошады. Анда барлык шартлар да тудырылган, миңа бернинди кыенлык белән дә очрашырга туры килмәде. Фрат университетының барлык биналары бер урында урнашкан. Ул үзенә күрә аерым бер территория кебек тоела. Бездән аермалы буларак, аларның төрле чара, кичәләр уздырыла торган махсус биналары бар. Ул «Ата төрек мәдәни мәркәз» дип атала. Студентлар арасында әллә ни аерма күрмәдем. Ике як студентлары да бик тырышып укыйлар. Шулай да, анда ничек кенә матур һәм рәхәт булмасын, Казан университеты миңа якынрак. Форсаттан файдаланып, КФУның барлык составына миңа шундый уникаль мөмкинлек тудырганы өчен рәхмәтемне белдерәм.

**- Төркиядә булган 8 ай эчендә иң истә калган нинди вакыйга булды?**

- 25-26 октябрьдә мин яшәгән Элазик шәһәрендә Г.Тукайга багышланган кичә уздырылды. Ул Татарстан, Казан белән берлектә үткәрелде. Анда укытучыларым Фәрит Йосыпов, Фәнзилә Җәүһәрова, шагыйрь Роберт Миңнуллин килгән иде. Ул вакытта туганнарымны күргән, Казаныма кайткан кебек хис иттем. Бу сәяхәттән шактый нәтиҗәләр чыгардым. Озак вакыт чит илдә булу – бик зур тәҗрибә. Мин яңадан-яңа дуслар таптым. Алар белән элемтәләр өзелмәс, алга таба да аралашырбыз, дип ышанам. Аннары чит ил үзенчәлекләре, менталитеты белән танышу һәрвакытта да кызык һәм күңелле.

● Хәйрия

# Изгелек җирдә ятмый

Җәйнең беренче көнен илебездә генә түгел, ә бөтен дөньяда Балаларны халыкара яклау көне буларак каршы алабыз. Һәм ул ай тулысы белән шул бәйрәм позитивында узып та китә.



Июнь ае – укучыларның җәйге ялга чыккан чоры да әле. Шуңа күрә бу айда төрледән-төрле чаралар уздырыла. Университетыбыз да әлеге вакыйгадан читтә калмый: КФУның Психология һәм мәгариф институты хәйрия чаралары атналыгы оештырды. Бер атна дәвамында Алексеевск, Апас, Яшел Үзән, Кайбыч, Тәтеш, Кама-Тамагы, Спас районнары һәм Яр Чаллы, Болгар, Казан шәһәрләренең белем бирү учреждениеләреннән мөмкинлекләре чикле, ятим, гаилә хәле имин булмаган балалар өчен онытылмас бәйрәм ясалды. Алар өчен республикабызның әдәбият һәм сәнгать әһелләре, КФУ галимнәре белән очрашулар, ТР Милли музеена, М.Җәлил, К.Насыйри, Г.Тукай, М.Горький музейларына һәм мәркәзебезнең башка бик күп тарихи урыннарына экскурсияләр оештырылды. Университетыбызның зоология, тарих музейлары да кунакларга үз ишекләрен ачты. Балалар, шулай ук, Казан зоопаркында, «Ривьера» аквопаркында, Г.Камал исемендәге академия театрында һәм Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театрларында булдылар.



КФУ ректоры И.Гафуров инициативасы белән балалар өчен атна буена хәйрия ашлары оештырылды. Хәйрия атналыгын уздыруда КФУның Психология һәм мәгариф институты хезмәткәрләре аеруча актив катнашты.

Һәр бала өчен әлеге атна онытылмас һәм кабатланмас бәйрәмгә, әкияткә әверелде. Психология һәм мәгариф институты оештырган хәйрия эше һәммәбез күңелендә яңа изге гамәлләр кылырга этәргеч булып торсын.

● Халәт

Җәй җиттеме, калабыз бушап калган кебек була: студентлар сессияләрен ябып, каникулга кайтып китәләр. Бик азга гына сузылган бу бушлыкны укырга дип төрле төбәкләрдән җыелган «яңа» студентлар юкка чыгара.

# Борчулы да, рәхәт тә...

**Алинә ХӘЙДӘРОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Бер белмәгән чит шәһәр, ят кешеләр. «Бәлки, болай ерак китмәскәдер?!» – дигән уй да керәдер күпләргә. Республикабызның башка шәһәрләрен хурлап әйтүем түгел, ләкин, хыялланган һөнәреңне үзләштерү өчен, Казанда мөмкинлекләр күп. Бары тик курыкмаска гына кирәк. Беренче айларда сагындыра, әлбәттә, ә аннан күнегәсең. Туган йортыннан читкә киткәннәрнең һәммәсен яңа дуслар, яңа танышлар, кызыклы вакыйгалар, гомумән, яңа тормыш көтә.

Әйе, бу бик тә борчулы вакыт – яңа мөстәкыйль студент тормышына беренче адым ясау. Мин үзем күптән түгел шушы хис-тойгылар аша үттем, шәһәргә килеп, бөек Казан федераль университеты студенты булдым. Кечкенәдән журналист булу хыялын тормышка ашырам. Шәһәргә ияләштем, өйрәндем, бик күп дуслар таптым. Студент булып караган һәр кеше бу чорны иң күңелле һәм кызык чак дип әйтә иде. Дөресе шул икән. Төркемдәшләрем бик яхшылар, шуңа, бәлки, уртак телне тиз таптык. Хәзер без бик тату һәм дус.

***P. S.*** *Бүгенге көндә дәүләт имтиханнарын тапшырып, аттестат алырга әзерләнүче укучыларга шуны әйтәсем килә: курыкмагыз, дусалрым, студент тормышы – бик кызыклы һәм кабатланмас чак. Тормыш юлыгызда тагын бер баскычка күтәрелергә курыкмагыз! Кыю һәм аралашучан булыгыз!*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.